ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.02.2025 г. Заинск № 83

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 17 декабрендәге 644 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына социаль ярдәм күрсәтү чараларын күрү максатларында, социаль яклау дәрәҗәсен арттыруга һәм, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 17 декабрендәге 644 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» карары белән расланган «Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләү өчен ата-аналар түләвен исәпләү, билгеләү һәм үзгәртү тәртибен" 2 нче кушымтаның II өлешенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә (08.07.2022 ел № 337, 23.05.2022 ел № 249, 03.10.2022 ел № 506, 07.12.2022 ел № 620, 07.04.2023 ел № 245, 16.07.2024 ел № 408 карарларда кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып):

1.1. Бишенче абзацның икенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затлар, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар, хәрби бурычларны ирекле рәвештә башкаручы гражданнар арасыннан махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның балалары

өчен махсус хәрби операция барышында Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән, шулай ук югарыда күрсәтелгән категориядәге гражданнарның махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган,яисә Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операция барышында бурычларны үтәгәндә инвалидлык алган яки Украина территорияләрендә хәрби операцияләр, Донецк Халык Республикасына, Луганск Халык Республикасына, Запорожье өлкәсенә һәм Херсон өлкәсендә махсус хәрби операциядә катнашкан хәрби хәрәкәтләр ветераннары балаларына ата-аналар түләве алынмый (законлы вәкилдән бирелгән гариза һәм хәрби комиссариаттан белешмә яки эш урыныннан белешмә нигезендә)».

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» нда түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 01 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Э.Р. Сафаргалиев
3-27-42